**Кукмара муниципаль районы**
**Важашур авыл җирлеге Советы**

# КАРАР

«15» апрель, 2025 ел № 9

**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында**

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы, 2007 елның 07 маендагы 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 25, 26 статьялары, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 38 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын ун ел вакытка расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны, бермандатлы сайлау округлары схемасын, аның график сурәтен дә кертеп, 2025 елның 19 апреленнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән (kukmor.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлеге торак пунктлары территориясендә түбәндәге адресларда урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә:

Починок Сутер авылы, Яшьләр ур., 1д й.(административ бина);

Югары Шөн ав., Октябрь ур., 22а й. (авыл клубы бинасы).

3. Карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Җирлек башлыгы П.Л. Иванов

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлеге Советының 2025 елның 15 апрелендәге 9 номерлы карарына кушымта

## Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасы

**1 номерлы Важашур сайлау округы**

Сайлау округына Важашур авылы территориясе, Починок Сутер авылы территориясенең Бакча урамындагы 1-3 нче йортлары керә.

Сайлаучылар саны - 85.

**2 номерлы Ленин сайлау округы**

Сайлау округына Починок Сутер авылы территориясенең Ленин урамындагы 19-44 нче йортлары, Бакча урамындагы 4-21 нче йортлары керә.

Сайлаучылар саны - 92.

**3 номерлы Яшьләр сайлау округы.**

Сайлау округына Починок Сутер авылы территориясенең Ленин урамындагы 1-18 нче йортлары, Яшьләр урамы, Яңа урам керә.

Сайлаучылар саны - 89.

**4 номерлы Иске Каенсар сайлау округы**

Сайлау округына Иске Каенсар авылы, Яңа Каенсар авылы территориясенең Мәктәп урамы, Гагарин урамының 3-17 нче йортлары керә.

Сайлаучылар саны - 100.

**5 номерлы Яңа Каенсар сайлау округы**

Сайлау округына Яңа Каенсар авылы территориясенең Гагарин урындагы 18-81 нче йортлары керә.

Сайлаучылар саны - 102.

**6 номерлы Чапаев сайлау округы**

Сайлау округына Югары Шөн авылы территориясенең Чапаев урамы керә.

Сайлаучылар саны - 92.

**7 номерлы Октябрь сайлау округы**

Сайлау округына Югары Шөн авылы территориясенең Октябрь ур., Май ур. керә.

Сайлаучылар саны - 98.

**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасының график сурәте**

